| | | |
|---|---|---|
| **МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯҺӘМ ТАБИГЫЙ БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ** |

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

21.07.2017 824-П

Эшкә яллаучы вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер генә кешеле башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт бирү тәртибе турында

“Россия Федерациясенең дәүләт гражданлык хезмәте турында” 2004 елның 27 июлендәге № 79-ФЗ Федераль законның 17 маддәсенең 1 өлешенең 3 пункты нигезендә боерык бирәм:

1. Кушымтада бирелә торган Эшкә яллаучы вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер генә кешеле башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт бирү тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.
2. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Министр Ф.С. Габделганиев

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигый
байлыклар министрыныың
21.07.2017 № 824-п
боерыгы белән расланды

Эшкә яллаучы вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер генә кешеле башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт бирү тәртибе

1. Эшкә яллаучы вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгында (алга таба – Министрлык) Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер генә кешеле башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт бирү тәртибе (алга таба – Тәртип ) “Россия Федерациясенең дәүләт гражданлык хезмәте турында” 2004 елның 27 июлендәге № 79-ФЗ Федераль законның 17 маддәсенең 1 өлешенең 3 пункты нигезендә эшләнде.

Әлеге Тәртип эшкә яллаучы вәкиле тарафыннан Министрлыкта Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәренә (алга таба – гражданлык хезмәткәрләре) иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативы, бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативы, күчемсез милек ияләре ширкәте (алга таба – коммерциячел булмаган оешма) белән идарә итүдә бер генә кешеле башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт бирү процедурасын регламентлый.

Әлеге Тәртип Министрлыктагы алар өчен эшкә яллаучы вәкиле булып Татарстан Республикасы экология һәм табигый байлыклар министры торган Татарстан Республикасы гражданлык хезмәткәрләренә кагыла.

2. Коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер генә кешеле башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт бирү турында гариза (алга таба – Гариза) гражданлык хезмәткәре тарафыннан әлеге Тәртипкә Кушымта №1 нигезендә язмача формада төзелә.

3. Гражданлык хезмәткәре Гаризаны ришвәтчелек һәм бүтән төр хокук бозуларны профилактикалау буенча эш өчен җаваплы затка (алга таба –Җаваплы зат) тапшыра.

4. Җаваплы зат Гаризаны аның кергән көненедә әлеге Тәртипкә Кушымта № 2 нигезендә форма буенча Журналда терки.

5. Җаваплы зат Гаризаны алдан карауны гамәлгә ашыра һәм аның нәтиҗәләре буенча бәяләмә әзерли.

Гаризаны алдан карау барышында Җаваплы зат Гариза биргән гражданлык хезмәткәреннән коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә планлаштырылган катнашу буенча функцияләрне билгели торган язмача аңлатмалар һәм документлар соратып алырга хокуклы.

Бәяләмәдә гражданлык хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер генә кешеле башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт бирү яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында тәкъдим булырга тиеш.

6. Гаризаны теркәгән көннән алып биш эш көненнән соңга калмыйча, Җаваплы зат Гаризаны, Бәяләмәне һәм башка материалларны (булган очракта) теркәп, Татарстан Республикасы экология һәм табигый байлыклар министрына (алга таба – Министр) (аның вазыйфаларын башкаручы затка) гражданлык хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер генә кешеле башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт бирү яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен карауга тапшыра.

Министр (аның вазыйфаларын башкаручы зат) Гаризаны алган көннән соң ике эш көне эчендә карар кабул итә.

7. Җаваплы зат Министр (аның вазыйфаларын башкаручы зат) карар кабул иткән көннән алып ике эш көне дәвамында гражданлык хезмәткәренә Гаризаны карау нәтиҗәләре турында хәбәр итә һәм аңа Министр резолюциясе куелган Гаризаның кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге мөһере белән расланган күчермәсен кул куйдырып тапшыра. Гаризаның Министр резолюциясе куелган төп нөсхәсе гражданлык хезмәткәренең шәхси делосына теркәлә.

Эшкә яллаучы вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер генә кешеле башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт бирү тәртибенә
Кушымта №1

___________________________________
___________________________________
_
(Ф.И.О., биләп торган вазыйфасы һәм структур
___________________________________
_
бүлекчә, яшәү урыны адресы
___________________________________
_
телефон номеры)

Эшкә яллаучы вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер генә кешеле башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт бирү турында
гариза

Миңа _____________________________________________________
(иҗтимагый оешма,
_____________________________________________________________________
__
торак, торак-төзелеш, гараж кооперативы, бакчачылык, яшелчәчелек,
_____________________________________________________________________
__
дача кулланучылар кооперативы, күчемсез милек ияләре ширкәте атамасы)
_____________________________________________________________________
__.
(бер генә кешеле башкарма орган яки коллегиаль идарә органы атамасы)
сыйфатында түләүсез нигездә
идарә итүдә катнашырга, коллегиаль идарә органы составына керергә
(кирәклесенең астына сызарга)
рөхсәт бирүегезне сорыйм

_____________ ___________________________ _______________
(дата) (имза) (фамилия, инициаллар)

Эшкә яллаучы вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер генә кешеле башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт бирү тәртибенә
Кушымта №2

Эшкә яллаучы вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер генә кешеле башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт бирү турында гаризаларны теркәү
ЖУРНАЛЫ

| № т/б | Дата | Гариза бирүченең Ф.И.О., вазыйфасы | Гариза бирүченең имзасы | Теркәүченең Ф.И.О. | Теркәүченең имзасы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |